Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

# КАРАР

2017 елның 14 феврале № 15/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районында авыл халкының эшлекле активлыгын
арттыру һәм авыл халкының кече рәвешләрен
үстерү һәм кече хуҗалыкларны үстерү
чаралары турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.И. Сарафановның «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм кече хуҗалыкларны үстерү чаралары турында» докладын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ :

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы урынбасары А.И. Сарафановның «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм кече хуҗалыкларны үстерү чаралары турында» докладын игътибарга алырга .

2. Авыл хуҗалыгын үстерүнең гамәлгә ашырыла торган федераль, республика һәм муниципаль программалары кысаларында авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. кече хуҗалыкларны үстерү, авыл халкының мәшгульлеген һәм керемнәрен арттыру, продукцияне сату күләмнәрен арттыру буенча кирәкле чаралар күрергә;

2.2. Өстәмә өлкәләрне һәм юнәлешләрне (умартачылыкны, сарыкчылыкны һ.б. өлкәләрне) киңәйтү, СМСПның актуаль өлкәләрен үстерү (кунакханә бизнесы, хезмәт күрсәтүләр өлкәсе, җәмәгать туклануы, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү һәм башкалар), халык кәсепләрен үстерү буенча планлы эш алып бару, ШЯХларга һәм СМСПга ярдәм итү программаларында катнашу, КФХ һәм ШЯХларга бәйле статистик хисап белешмәләренә мониторинг ясау;

2.3. Фермер хуҗалыкларын, шул исәптән гаилә терлекчелек фермаларын үстерү белән шөгыльләнергә теләк белдергән гражданнарга һәртөрле юридик, консультатив ярдәм күрсәтергә;

2.4. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга эре мөгезле терлекләрне, шул исәптән сыерларны, кәҗәләрне, сарыкларны һәм кошларны саклап калу буенча гына түгел, аларның баш санын арттыру буенча да ярдәм күрсәтергә;

2.5. авыл җирлеге Советы утырышында кече һәм урта эшмәкәрлекнең уңышлы субъектларын, авыл активын һәм авылда туып – үскән якташларны чакырып, авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү мәсьәләсен карау;

2.6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.03.2016 ел, №138 карары белән расланган шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга ярдәм итү чаралары буенча халык арасында мәгълүмат-консультация эшен яхшырту һәм әлеге программаларда катнашучылар санын арттыруга ярдәм итү;

2.7. авыл хуҗалыгы формированиеләре җитәкчеләре белән берлектә яшьләрне авылга беркетү буенча максатчан эш алып барырга, һәр студент белән, югары уку йортын тәмамлаганнан соң, урта махсус уку йортын Чүпрәле районына кайтару максатыннан, индивидуаль эш алып барырга.

3. Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетына:

3.1. кече бизнесны үстерү программалары буенча халык арасында мәгълүмат-консультация эшен яхшырту, «Лизинг-грант», «Яшь фермерларга ярдәм итү», «гаилә терлекчелек фермаларын үстерү», «миниферма төзү», «сәнәгать паркы резидентларына чыгымнар өлешен субсидияләү» һәм бу программаларда катнашучылар санын арттыруга ярдәм итү;

3.2. Авыл халкының инициативаларын стимуллаштыру, кече хуҗалыкларны һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү максатыннан төрле конкурслар оештырырга, аларга район Авыл хуҗалыгы һәм Сабантуй алдынгылары Слетында йомгак ясарга:

- районның иң яхшы шәхси ярдәмче хуҗалыгына;
- районның иң яхшы КФХларына;
- кече хуҗалыкларны үстерү буенча районның иң яхшы авыл җирлегенә.

4. Чүпрәле муниципаль районының «Эшкуарлыкка ярдәм итү үзәге» АНО авыл җирлекләре башлыклары белән берлектә эшкуарлык үсешенә ярдәм итүнең барлык төрләрен күрсәтү буенча максатчан гамәли эш алып барырга тәкъдим итәргә, шул исәптән документларны рәсмиләштергәндә дә.

5. «Туган як» газетасы редакциясенә авыл халкының эшлекле активлыгын арттыру, аларның шәхси хуҗалыкларына ярдәм итү һәм кече хуҗалыкларны, шул исәптән гаилә фермаларын үстерү мәсьәләләрен даими рәвештә яктыртырга тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чүпрәле муниципаль районы Советының икътисад, инвестицияләр, авыл хуҗалыгы, җир мәсьәләләре, эшкуарлык һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: А. В. Шадриков